Республика Татарстан
ГЛАВА ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
423950, п.г.т.Уруссу ул.Пушкина, 38
тел.: (85593) 2-80-13
факс: (85593) 2-62-20

Татарстан Республикасы
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ
423950, Урыссу ш.т.б. Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-80-13
факс: (85593) 2-62-20

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

“ 19 ” 11 2021г. № 96

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы район Советының «2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 28 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында яшәүчеләрнең 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты проектын тикшерүдә катнашу хокукларын үтәү максатларында, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2020 елның 28 апрелендә №18 карары белән кабул ителгән "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2018 елның 4 октябрендәге 33 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәсе нигезендә,
карар бирәм:

1. «2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар планлы чорына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгы гавами тыңлаулар үткәрү инициаторы булып тора.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

- үткәрү вакыты: 2021 елның 30 ноябрендә, 17 сәгать 30 минутта;

- үткәрү урыны: Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Урыссу ш.т.п., Пушкин ур., 38 й., Татарстан Республикасы Ютазы район Советының утырышлар залы;

- тикшерелүче сорау буенча язма тәкъдимнәр һәм замечаниеләр тәкъдим итәргә мөмкин булган адрес: Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Урыссу ш.т.п., Пушкин ур., 38 йорт, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты.

4. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетына, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының норматив хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда «2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Ютазы район Советының гамәлдәге карар проекты буенча гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

5. «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Ютазы район Советының карар проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү буенча оештыру комитеты (эш төркеме) составын кушымта нигезендә расларга.

6. «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карары проектын Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Ютазы муниципаль районы Башлыгы А. Ә. Шәфигуллин

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы карарына

Кушымта
_____________ 2021 ел №___

«2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Ютазы район Советының карар проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү буенча оештыру комитеты (эшче төркем) составы

| | |
|---|---|
| Самонина С. П. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, оештыру комитеты (эшче төркем) рәисе (килешү буенча) |
| Сучкова А.В. | Ютазы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе урынбасары, оештыру комитеты (эшче төркем) секретаре (килешү буенча) |
| Оештыру комитеты (эшче төркем) әгъзалары | |
| Мөхәммәтова Р.Г. | Ютазы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Галиев С.Ә. | Татарстан Республикасы Ютазы районы Советының 2 нче номерлы Бәйрәкә сайлау округыннан депутат, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының Бюджет, салымнар, инвестицияләр һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясе рәисе |
| Хисмәтуллин Р.В. | Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 10 нчы номерлы Техснаб сайлау округыннан депутат, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының Бюджет, салымнар, инвестицияләр һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясе рәисе урынбасары |
| Якупов Р. М. | Татарстан Республикасы Ютазы район Советының юридик бүлеге начальнигы |
| Муллагалиева Р.К. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иҗтимагый Советы рәисе (килешү буенча) |